**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 август № 562

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 ел, 10 октябрь, ТРЗ-77 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2011 ел, 6 декабрь, 999 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 ел, 10 октябрь, ТРЗ-77 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2011 ел, 6 декабрь, 999 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 декабрь, 1098 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гариза бирү, рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү тәртибендә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бу Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гариза бирү, рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату, рөхсәт дубликатын бирү механизмын билгели.»;

түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Рөхсәтнең гамәлдә булуы ул бирелгән вакыт үткәннән соң яисә түбәндәгеләр нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән соң туктала:

1) юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең үзенә бирелгән рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында юридик затның даими гамәлдә булган башкарма органы җитәкчесе яки бу юридик зат исеменнән эш итәргә хокукы булган бүтән зат яки шәхси эшмәкәр, яки, ышанычнамә беркетеп, юридик затның яисә

шәхси эшмәкәрнең вәкиле имзалаган гаризасы (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча);

2) җиңел такси сыйфатында файдаланыла торган транспорт чарасы милекчесенең, транспорт чарасына милек хокукын раслый торган документның таныкланган күчермәсе теркәлгән, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гаризасы (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча);

3) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрына рөхсәт алган физик затның шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеге тукталу турында язуны кертү хакында мәгълүмат алу;

4) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына рөхсәт алган юридик затның эшчәнлеге тукталу турында язуны кертү хакында мәгълүмат алу;

5) Рөхсәтне кире алу (бетерү) турында суд карарының законлы көченә керүе.

Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гариза кәгазьдәге документ рәвешендә турыдан-туры вәкаләтле органга яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре аша бирелә.

Вәкаләтле орган гаризаны теркәгәннән соң яисә әлеге пунктта күздә тотылган мәгълүматны алган көннән соң 10 эш көне эчендә рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул итә.

Вәкаләтле органның рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карары боерык рәвешендә рәсмиләштерелә. Карар Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бирелгән рөхсәтләр реестрына үзгәрешләр кертү юлы белән кабул ителгән һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә рәсми сайтта урнаштырылган көннән соң биш эш көне эчендә мәнфәгатьле затлар игътибарына җиткерелә.

Түбәндәге очракларда рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату рөхсәт ителми:

1) гариза тиешле формада бирелмәсә;

2) дөрес рәсмиләштерелмәгән гариза бирелсә;

3) вәкаләтләре булмаган юридик зат яки шәхси эшмәкәр гариза бирсә;

4) документлар тулы булмаган комплектта бирелсә;

5) әлеге рөхсәтне алмаган шәхси эшмәкәр яки юридик зат гариза бирсә;

6) әзерләнгән рөхсәт алынмаса.»;

2.1 пунктта «1 нче кушымтага» һәм «2 нче кушымтага» сүзләрен тиешенчә «2 нче кушымтага» һәм «3 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта «күчермәсе» сүзеннән соң «яки икенче данәсе» сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктта:

«Бер эш көне эчендә» сүзләрен «Ике эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

«гариза бирүчегә кире кайтаруның сәбәбе:» сүзләреннән соң «турыдан-туры яки» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта «Бер эш көне эчендә» сүзләрен «Ике эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта «3 нче кушымтага» сүзләрен «4 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта «Бер эш көне эчендә» сүзләрен «Ике эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта «4 нче кушымтага» һәм «5 нче кушымтага» сүзләрен тиешенчә «5 нче кушымтага» һәм «6 нчы кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта «6 нчы кушымтага» һәм «7 нче кушымтага» сүзләрен тиешенчә «7 нче кушымтага» һәм «8 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктка «күчермәсе» сүзеннән соң «яки икенче данәсе» сүзләрен өстәргә;

Тәртипкә 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгәннәр);

Тәртипкә 8 нче кушымта өстәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бирелгән рөхсәтләр реестрын алып бару тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле орган түбәндәге көннән соң өч эш көне эчендә язуны реестрга кертә:

рөхсәт бирү, аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән;

юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге куелган таләпләр һәм шартлар бозылган өчен административ туктатып торылган очракта рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору, шулай ук аның гамәлдә булуын торгызу турында карар кабул итү;

рөхсәтне кире алу (бетерү) турында суд карарының законлы көченә керүе.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле «о» һәм «п» пунктчалары өстәргә:

«о) транспорт чарасының төсе;

п) транспорт чарасын теркәү турында таныклыкның сериясе һәм номеры.»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле  абзац өстәргә:

«Реестрдан дөрес булмаган мәгълүматны чыгару максатында Вәкаләтле орган елына кимендә ике тапкыр ведомствоара электрон багланышлар системасы ярдәмендә рөхсәт алган шәхси эшмәкәрләр яки юридик затлар статусы турында тиешенчә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков